КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 август г.Казань № 684

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче, 2013 ел, 20 август, 585 нче, 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче, 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август. 595 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә, 3 бүлекнең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.2 Агентлык түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01)*;

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01)*;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү (01.02.1)*;

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3)*;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – хезмәтне саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13.02)*;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01)*;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорттан, җиһазлардан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү (01.07.01)*;

Татарстан Республикасы милкендәге акцияләр (өлешләр) пакетыннан файдалану белән идарә итү (01.07.02)*;

Татарстан РеспубликасыЮстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01)*;

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03)*;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән мәгълүматлаштыру белән – идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15)*;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – шәһәр төзелеше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.05)*;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән – табигый байлыклардан файдалану, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06)*;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән – авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02)*;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән – транспорт комплексы белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03)*;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән – сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02)*;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән – мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диндәге дини берләшмәләр арасында үзара килешүне һәм түземлелекне ныгытуга булышлык күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (04.03)*;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән – физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04)*;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05)*;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы белән – дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07)*;

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты белән – архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03)*;

эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары белән;

эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары белән.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин